Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске-Рәҗәп авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карары

01 декабрь 2021 ел №6

Спас муниципаль районы Иске-Рәҗәп авыл җирлеге
торак пунктта 2022 елда гражданнарның үзара салымы
кертү һәм куллану чаралары
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Спас муниципаль районы Иске-Рәҗәп авыл җирлеге Уставының 22 ст., "Спас муниципаль районы Иске-Рәҗәп авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы»

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1.Татарстан Республикасы, Спас районы, Иске-Рәҗәп авылы, Ленин урамы, 39а йорт адресы буенча урнашкан Иске-Рәҗәп авылы мәдәният йорты бинасында 2021 елда Спас муниципаль районы Иске-Рәҗәп авыл җирлегенең Иске-Рәҗәп торак пунктында граңданнар узара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 21 декабренә 10.00 сәгатьтә билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: "Сез 2022 елда Спас муниципаль районы Иске-Рәҗәп авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче гражданнардан тыш 700 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Иске Рәҗәп авылында урамнарны яктырту, энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү);

- Иске Рәҗәп авылында җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);-

Иске Рәҗәп авылында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

- агач кисү, кисү һәм утильләштерү, шулай ук Иске Рәҗәп авылында гербицидлар сиптерү (килешү буенча эш өчен түләү);

- Иске Рәҗәп авылында яшәүчеләрне радиоэлемтә хезмәтләре белән тәэмин итү (материаллар сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

-Иске Рәҗәп авылында чүплекләрне механикалаштырылган буртлау ,чүп –чар мәйданчыкларын карап тоту (килешү буенча эш өчен түләү, транспорт хезмәтләре өчен түләү);

- Иске Рәҗәп авылындагы М. Җәлил урамы, Ленин урамы, Байтерман урамы, Чурай урамы эчендәге юлларны ремонтлау, урам юлларын бетонлау ( вак таш, гравий, материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Иске Рәҗәп авылында Ленин һәм Җәлил урамындагы җәяүлеләр күперен ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Иске Рәҗәп авылында мини-футбол кырын чабу очен чапкыч сатып алу;

-,Иске Рәҗәп авылында бәйрәмнәр оештыру һәм уткәрү Җиңү көне, Нәүрүз, Сабантуй (Авыл көне), Өлкәннәр көне, Яңа ел( чараларны оештыру, бүләкләр, сувенирлар сатып алу;);

- Иске Рәҗәп авылында Ленин урамындагы парк коймасын тоту (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Иске Рәҗәпавылында Ленин урамындагы парк территориясен җиләк-җимеш агачлары һәм куаклар белән яшелләндерү (яшел үсентеләр сатып алу);

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (htth:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, җирле радио аша тапшырырга кирәк.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске-Рәҗәп авыл җирлеге башлыгы М.Ә.Нугаев